# ХАЛЫК ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы Войкино авыл җирлеге составына керүче Войкино авылы

10 ноябрь 2019 ел. № 2

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының Войкино авыл җирлеге составына керүче Войкино торак пунктында гражданнар җыены

**Карар итте**:

1. 2020 елда Войкино авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешегә, 1 нче төркем инвалидлардан, көндезге бүлектә укучы студентлардан, Россия Армиясе сафларына чакырылган гражданнардан тыш, 400 сум күләмендә үзара салым кертергә.
2. Алынган акчаларны түбәндәге чараларга юнәлдерергә:
   - җирлек эчендәге юлларны карап тоту;
   - торак пунктлардагы урамнарны төзекләндерү һәм карап тоту;
   - Войкино авылында чишмәне төзекләндерү;
   - су белән тәэмин итү челтәрләрен карап тоту;
   - торак пунктларда урамнарны яктыртуны карап тоту;
   - балалар мәйданчыгы сатып алу.

3. Әлеге карарны Войкино авыл җирлегенең рәсми сайтында, хокукый мәгълүмат порталында, шулай ук Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы Войкино авыл җирлеге Советы бинасында мәгълүмат стендында урнаштырырга.

4.Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары Регистрына кертү өчен җибәрергә.

**Гражданнар җыенында рәислек итүче,**
**Войкино авыл җирлеге башлыгы Н.П.Шабутдинова**